ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 52

П Р И К А З　　　　　　　　Б О Е Р Ы К

«12» 02. 2016 ел

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” № 273-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт вазифаларын биләүче затлар һәм бүтән затлар тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” № 650 Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Кадрлар бүлеге башлыгына (Н.Н. Никитина) әлеге Боерык белән Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендәге дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен,

шулай ук алар белән хезмәт контрактларын төзегәндә гражданнарны таныштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Башлык С.А.Крайнов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясе
башлыгының 2016 елның
12 февралендәге
№ 52 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан
вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки
китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында
хәбәр итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә Дәүләт торак инспекциясе башлыгы аларга карата эшкә алучының вәкиле булып торган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – ТР ДТИ, гражданлык хезмәткәрләре) тарафыннан вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен регламентлый.

2. Хәбәр гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан шушы Тәртипкә карата Кушымтада китерелгән вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү белдерүнамә (алга таба – белдерүнамә) рәвешендә язмача төзелә һәм башлыкка җибәрелә.

3. Башлык өч эш көне дәвамында белдерүнамәне беренчел карап тикшерү өчен коррупцияне һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Белдерүнамәне беренчел карап тикшерү барышында җаваплы зат белдерүнамәне җибәргән гражданлык хезмәткәреннән анда бәян ителгән шартлар буенча аңлатмалар алырга, билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына, башка җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга гарызнамәләр җибәрүнең инициаторы булырга хокуклы.

5. Белдерүнамәне беренчел карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат нигезле бәяләмә әзерли. Беренчел карап тикшерү барышында алынган белдерүнамә, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат белдерүнамәне алган көннән башлап җиде эш көне дәвамында аның тарафыннан ТР ДТИ Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Шушы Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләрне җибәргән очракта, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан Комиссия рәисенә белдерүнамәне алган көннән соң 45 көн дәвамында тапшырыла. Аталган вакыт Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән артмаган чорга озынайтылырга мөмкин.

7. Белдерүнамә, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан ТР ДТИнең 2016 елның 12 февралендәге № 53 боерыгы белән расланган ТР ДТИ Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә нигезендә карап тикшерелә.

Татарстан Республикасының
Дәүләт торак инспекциясендә
Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан
вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә
мәнфәгатьләр каршылыгына
китерә торган яки китерергә
мөмкин булган шәхси
кызыксынучанлык барлыкка
килү турында хәбәр итү
тәртибенә карата кушымта

______________________________________________
(танышып чыгу турында тамга)

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясе
башлыгына
___________________________
кемнән
___________________________
___________________________
___________________________
(Ф.И.А., били торган вазифа, адрес,
телефон номеры)

Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына
китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык
барлыкка килү турында
БЕЛДЕРҮНАМӘ

Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган (*кирәклесе астына сызарга*) шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү өчен нигез булган шартлар:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлык аларның үтәлешенә йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вазифаи вәкаләтләр:______________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ______________________________________________________
__________________________________________________________________________

Шушы белдерүнамәне карап тикшергәндә Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим / ниятләмим (*кирәклесе астына сызарга*).

«____» _____________ 20___ ел. ________________________ ___________________________

(белдерүнамә җибәргән затның имзасы) (имзаның аңлатмасы)